ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

27.01.2022　　　　　　　　　　03-10/03

с. Русское Макулово

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегендә 2022нче елга җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 12.01.1996 ел, №8-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирләү һәм җирләү турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 6964,68 сум күләмендә хезмәт күрсәтү бәясен 2022 нче елның 1 нче февраленнән башлап 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Макыл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетыны җитәкчесе　　　　Р. В. Гусева

Югары Ослан муниципаль
районы Макыл авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның 27 гыйнвары,
03-10/03 номерлы карарына
1 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы  Макыл авыл җирлегендә
2022нче елның 1нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең
гарантияле исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2.  Табут һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3601,24 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка озату | 1116,65 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2246,79 |
| Барлыгы | 6964,68 |

Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2022 елның 27 гыйнвары,
03-10/03 номерлы карарына
2 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегендә 2022нче елның 1нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәетне кәфенләү | 666,35 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 2934,90 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка илтү | 1116,65 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2246,78 |
| Барлыгы | 6964,68 |